**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Старочелнинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Чаллы авыл Жирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422876, РТ, с. Старые Челны, ул. Центральная, 20
тел: : 8 (84346) 79-4-53

Адресы: 422876, РТ, Иске Чаллы авылы, Центральная ур. 20
факс: 8 (84346) 79-4-53

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 20 марты** **Иске Чаллы** **11№**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы "Җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымта нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 29 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru.порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: М.Г.Исхаков

Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 мартындагы 11 номерлы карарына 1 нче кушымта

Иске Чаллы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б№ | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3700,80 |
| 3. | Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 1336,39 |
| 4. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1387,79 |
| | Барлыгы: | 6424,98 |

Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 мартындагы 11 номерлы карарына 2 нче кушымта

Иске Чаллы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б№ | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Кәфенләү(төрү, киендерү) | 1234,23 |
| 3. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2461,43 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 1336,39 |
| 5. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1392,93 |
| | Барлыгы: | 6424,98 |